**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылы торак пунктында
2025 елда үзара салым кертү турында

**2024 ел, 19 ноябрь** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1)Чукмарлы торак пунктында урамнарда яктырту җайланмасы (лампаларны, энергияне сак тотучы тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру);

2)Чукмарлы торак пункты территориясен төзекләндерү (мәдэният йорты территориясенен тротуарын ремонтлау,мәгълүмәт стенды урнаштыру, территорияне кышкы чорда кардан чистарту,ягулык- майлау материаллары сатып алу, МТЗ-82 тракторына эленмэ жайланмалыры очен запчастьлар сатып алу);

3)Чукмарлы торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су җыю манарасын ремонтлау)

4) Чукмарлы торак пунктында һәйкәлләр төзү, аларны ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр булмаган) керү юлын ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (газон чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу).

3. Жыен нэтижэлэрен Чукмарлы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Хадиуллин